КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 23 сентябрь г.Казань № 910

Инвалидларны билгеләнгән квота чикләрендә эшкә кабул итүне төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Инвалидларны билгеләнгән квота чикләрендә эшкә кабул итүне төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы территориясендә инвалидларны билгеләнгән квота чикләрендә эшкә кабул итүне төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тотуны гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы булып Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тора дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы территориясендә тикшерүләр үткәрү, үтәү өчен мәҗбүри булган күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр төзү хокукы белән инвалидларны билгеләнгән квота чикләрендә эшкә кабул итүне тикшерүдә тотуны һәм аңа күзәтчелек итүне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2017 ел, 30 ноябрь, 924 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә тикшерүләр үткәрү, үтәү өчен мәҗбүри булган күрсәтмәләр

бирү һәм беркетмәләр төзү хокукы белән инвалидларны билгеләнгән квота чикләрендә эшкә кабул итүне тикшерүдә тотуны һәм аңа күзәтчелек итүне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2017 ел, 30 ноябрь, 924 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә тикшерүләр үткәрү, үтәү өчен мәҗбүри булган күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр төзү хокукы белән инвалидларны билгеләнгән квота чикләрендә эшкә кабул итүне тикшерүдә тотуны һәм аңа күзәтчелек итүне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2020 ел, 22 сентябрь, 856 нчы.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин